**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**15.11.2024 ел** **№ 130**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 45 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма үтәвенә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 45 номерлы карары белән расланган (2021 елның 03 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 64 номерлы, 2023 елның 24 апрелендәге 95 номерлы, 2023 елның 22 ноябрендәге 114 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы үтәвенә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары" нигезләмәсенә 2нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (декарарга 1нче кушымта).

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы рәисе Д.А. Ишкинеев

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2024 елның 15 ноябрендәге 130 номерлы карарына 1нче кушымта

(«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре»муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контроль турында нигезләмәгә 2нче кушымта)

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Бер үк җылылык белән тәэмин итү объектларында өч ай рәттән ике һәм аннан күбрәк авария булганда.

2. Җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның өчен җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән Җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча кирәкле чаралар исемлеген, шулай ук әлеге чараларны үтәү срокларын бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан үтәмәү.

3. Контроль чара йомгаклары буенча бирелгән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан үтәлеше турында мәгълүмат булмау.

4. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан билгеләнгән вакытта мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турындагы кисәтүнең үтәлеше турында хәбәрнамә бирелмәү (вакытында бирелмәү).

5. Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, гражданнарның, оешмаларның, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының мөрәҗәгатьләрендә (гаризаларында) бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың мәҗбүри таләпләрне бозуы турында мәгълүматның булуы.